РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«25» декабрь 2024 ел Олы Кайбыч ав. № 302

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советының авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында карарын кабул итәргә:

- ял вакытын оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгы урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин